СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.10.2015 г.Агрыз № 2-5

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Әгерҗе муниципаль районында бюджет процессы турында»2013 елның 15 ноябрендәге 28-5 номерлы карары нигезләмәләренең пунктларының гамәлдә булуын туктатып тору хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 48 статьясы, "2016 елга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары проектларын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм "Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында" Федераль законның 3 статьясындагы үз көчен югалтуын тану хакында " 30.09.2015 № 273-ФЗ Федераль закон нигезендә, Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Әгерҗе муниципаль районында бюджет процессы турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 28-5 номерлы Әгерҗе муниципаль районы Советы карары белән расланган Әгерҗе муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше фаразыннан тыш, 2016 елның 1 гыйнварына кадәр 2 пунктның 1 абзацы һәм 3 пунктның 1 абзацы, 11 статьяның 1 пунктының 1 абзацы һәм 6 пунктның 1 абзацы, 6 пунктның 1 һәм 3 абзацлары, 19 статьяның 1 абзацы, 23 статьяның 1 абзацы, 25 статьяның 2 пунктының 1 абзацы (план чоры өлешендә), Әгерҗе муниципаль районының бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре, Әгерҗе муниципаль районының салым сәясәтенең төп юнәлешләре гамәлдә булуын туктатып торырга.

2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга, http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча Даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе В.В.МАКАРОВ